**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
от 21.11.2019

КАРАР
№ ПР-269

**“ТР Актаныш авылында Аэропорт, Химиклар, Фадеев, Миңнуллин, Басыйров, Сафаргалин, Минаев, Маликов, Авзал урамнарына газүткәргечне тармакландыру” объекты өчен территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары, территорияне тотрыклы үстерүне һәм планлаштыру структурасы элементларын аерып күрсәтүне тәэмин итү максатларында, 16.10.2019 елгы гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча беркетмәләрне һәм бәяләмәләрне карап чыкканнан соң,Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе «Баш территориаль проект-тикшеренү фәнни-җитештерү фирмасы «ТАТИНВЕСТГРАЖДАНПРОЕКТ», “ТР Актаныш авылында Аэропорт, Химиклар, Фадеев, Миңнуллин, Басыйров, Сәфәргалин, Минаев, Маликов, Авзал урамнарына газүткәргечне тармакландыру” объекты өчен территорияне ызанлау проектын раслау турында Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге территориясе буенча уздырыла торган «Актаныш муниципаль районы Актаныш авылында Аэропорт, Химиклар, Фадеев, Миңнуллин, Басыйров, Сәфәргалин, Минаев, Маликов, Авзал урамнарына газүткәргечне тармакландыру» объекты өчен тәкъдим ителгән планлаштыру проектын һәм межалау проектын расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны инфраструктура үсеше буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.И. Гариповка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И. И. Габдулхаев**